| СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге » муниципаль берәмлегенең Алексеевск штб торак пунктында граждannар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 елның 27 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 10.10.2022, 12.10.2022, 14.10.2022, 17.10.2022, 19.10.2022, 21.10.2022, 24.10.2022, 25.10.2022, 26.10.2022, 27.10.2022 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2023 елда Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,Бөек Ватан Сугышында катнашучылардан һәм сугыш инвалидларыннан,тыл ветераннарыннан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан,үз карамакларында 18 яшькә кадәрге 3 балалы гаиләләрдән тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- балалар уен мәйданчыкларын сатып алу һәм урнаштыру;
- урамнарны һәм ял зоналарын төзекләндерү һәм яшелләндерү;
- һәйкәлләр төзү һәм төзекләндерү;
- зиратларны карап тоту һәм төзекләндерү
- су һәм канализация челтәрләрен төзү һәм реконструкцияләү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Алексеевск шәһәр тибындагы бистә башкарма комитетына акчаны җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 8271 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 4631 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 3798 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 833 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге » Алексеевск штб торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныргa: «Сез 2023 елда Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,Бөек Ватан Сугышында катнашучылардан һәм сугыш инвалидларыннан,тыл ветераннарыннан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан,үз карамакларында 18 яшькә кадәрге 3 балалы гаиләләрдән тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- балалар уен мәйданчыкларын сатып алу һәм урнаштыру;
- урамнарны һәм ял зоналарын төзекләндерү һәм яшелләндерү;
- һәйкәлләр төзү һәм төзекләндерү;
- зиратларны карап тоту һәм төзекләндерү
- су һәм канализация челтәрләрен төзү һәм реконструкцияләү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Алексеевск шәһәр тибындагы бистә башкарма комитетына акчаны җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән 10 көн эчендә Алексеевск шәһәр җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Татарстан Республикасы Алексеевск**
**муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге »**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** ____________ **С.А. Демидов**